КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 30 июль г.Казань № б-1448

1. Түбәндәгеләрне расларга:

«Электр челтәрләренә технологик тоташтыру» максатчан моделен;

«Электр челтәрләренә технологик тоташтыру» максатчан моделен кертү буенча чаралар планын («юл картасын») (алга таба – юл картасы).

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына, кызыксынучы оешмалар белән берлектә, бу боерык белән расланган «юл картасы» чараларын тормышка ашыруны тәэмин итәргә һәм ай саен, хисап аеның 20сенә кадәр, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына «юл картасы» чараларын тормышка ашыру барышы турында мәгълүмат бирергә.

3. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына ай саен:

хисап аеннан соң килә торган айның 1енә кадәр «юл картасы» чараларын тормышка ашыру барышы турындагы җыелма хисапны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кертергә;

хисап аеннан соң килә торган айның 1еннән 5енә кадәр «Электр челтәрләренә технологик тоташтыру» максатчан моделе күрсәткечләренең агымдагы мәгънәләрен Region-id мәгълүмат системасына кертүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 9 июнь, б-1237 нче боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин